

Республикабыз мәктәпләрендә, шул исәптән татар мәктәпләрендә дә, 9нчы, 11нче сыйныфларны тәмамлаган 10 менгә якын укучы очен тантаналы линейкалар, традицион концертлар һәм башка торле чаралар узды.
Чыгарылыш сыйныф укучыларын Мордовия Республикасы Главасы Артём Алексеевич Здунов болай котлады:
- Кадерле чыгарылыш укучылары!
Сезне һәр кеше тормышындагы моһим һәм дулкынландыргыч вакыйга - мәктәп юлын тәмамлау белән котлыйм! Бvген сез момкинлекләр белән тулы яна мавыктыргыч этап бусагасында басып торасыз.      Сезнен алда барлык ишекләр дә ачык. Максатлар куегыз һәм ышаныч белән аларга барыгыз. Исегездә тотыгыз, унышка юл белем, хезмәт союченлек һәм максатчанлык аша уза.



Быел Мордовия мәктәпләренен тугызынчы һәм унберенче сыйныфларын тәмамлаган 10 меннән артык кеше олы тормыш юлына басачак. Һәркемнен уникаль таланты һәм чиксез потенциалы бар. Аларны vз идеяләрегезне тормышка ашыру һәм киләчәк профессионаллары булу очен кулланыгыз. Масштаблы хыялланырга курыкмагыз. Ватаныгыз белән горурланыгыз, ана булган мәхәббәт сезне игелекле эшләргә рухландырсын. Сезне жылылык һәм сабырлык белән унышка алып барган әти-әниләрегезгә, укытучыларыгызга һәм остазларыгызга аерым рәхмәт белдерәм. Аларнын ярдәме белән сез бу авыр, кайчак чәнечкеле юлны vтә алдыгыз. Алар сезгә батырлык һәм ватанпәрвәрлек дәресләре бирделәр, традицияләребезгә һәм кыйммәтләребезгә хормәт тәрбияләделәр. Аларнын мәхәббәте һәм игътибары озак еллар



сезнен очен коч һәм илһам чыганагы булып калачак. Сезгә имтиханнарда унышлар, vз кочегезгә ышаныч, яна белемнәргә һәм казанышларга даими омтылыш телим! Тормыш юлыгыз якты, киләчәгегез шатлыклы булсын!
Чыгарылыш сыйныф укучыларын укытучылары, ата-аналары, кин жәмгыять вәкилләре котлап, Мордовиянен, Россиянын vсеше сезнен белемегезгә бәйле булачак икәнен әйттеләр, кече Ватаннарына тугры гражданнары булачакларына, мәктәпләрен, укытучыларын онытмаячакларына ышанычларын белдерделәр.